ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 март, 2025 ел № 43/8

2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планына (программасына) үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмә нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2024 елның 6 декабрендәге 39/10 номерлы Карары белән расланган 2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планына (программасына) 5 пунктны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«5. 2025 елда Шәһәр Советының 2023 елның 6 декабрендәге 28/11 номерлы Карары белән расланган 2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фараз планына (программасына) кертелгән һәм хосусыйлаштырылмаган объектлар хосусыйлаштырылырга тиеш.

2025 елда үзгәртү планлаштырылган Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиеләре:

| № т/б | Предприятие исеме | Адресы | Икътисадый эшчәнлекнең төп төре | Үзгәртү |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Мәдәният һәм ял парκы» Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиесе | 423821, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Мир проспекты, 81 йорт | Башка төркемнәргә кертелмәгән башка тамаша-күңел ачу эшчәнлеге | Устав капиталында 100% муниципаль берәмлек өлеше белән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | «Шәһәр коммуналь хуалыгы» Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиесе | 423801, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Лермонтов урамы, 54 йорт | Коры җир пассажир транспорты эшчәнлеге: шәһәр һәм шәһәр янында пассажирлар йөртү | Устав капиталында 100% муниципаль берәмлек өлеше белән акционерлык җәмгыяте |

»

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев